| | | |
|---|---|---|
| **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ БАЙСАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**<br><br>423745, Иске Байсар авылы, Мәктәп ур., 44а йорт | | **СОВЕТ СТАРОБАЙСАРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**<br><br>423745, село Старое Байсарово, ул. Школьная, д. 44а |

**КАРАР**
**17 .09.2019**

**Решение**
**№23**

**Референдум үткәрү инициативасы турында**

12.06.2002 ел,№ 67-ФЗ "Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль законның 15 статьясы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, "Җирле референдум турында" 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12, 17 статьялары, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының "Иске Байсар авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә, Актаныш муниципаль районы Иске Байсар авыл җирлеге Советы

**Карар чыгарды:**

1. Түбәндәге мәсьәлә буенча җирле референдум үткәрүне инициировать итергә:

"2020 елда 18 яшькә җиткән, яшәү урыны җирлек чикләрендә теркәлгән һәр гражданнан 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертүгә, аларның җирле референдумда катнашуына һәм тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләренә бәйсез рәвештә, көндезге формада белем алучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, аларның саны җирлек халкының гомуми санының 30 процентан да артмый, алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү турында:

-Җирлектәге, җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларның эшчәнлеген тәэмин итү:
-юлларны төзекләндерү һәм карау;
җирлек халкын су, газ, электр, җылылык, ягулык белән тәэмин итү һәм суны чыгару өчен:
- су үткәргечләрен төзекләндерү, җирлектәге чишмәләрне рәсмиләштереп лизенция алу;
-җирлекне төзекләндерүне оештыру өчен:
- җирлектә беренчел янгын сүндерү чараларын тәэмин итү;
- җирлектә тарихи истәлекләрне саклау, файдалану һәм таныту:
- җирлек халкына ял итү урынын булдыру һәм шартлар тудыру;
- җирлектә һәм Яңа Байсар авылында стеллалар урнаштыру;
-җирлектә ритуаль хезмәт оештыру һәм зиратларны төзекләндерүне

**"ӘЙЕ "** **"ЮК"**

2. Әлеге карар махсус мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча урнаштырылган: ТР, Актаныш муниципаль районы, Иске Байсар авылы, Мәктәп ур., 44а йорт, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмати порталында һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Иске Байсар авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштыр.

3. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы Р.М.Кадыйров